КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 апрель г.Казань № 251

Татарстан Республикасында проект офисы рәвешендә Татарстан Республикасы фармацевтика сәнәгатен үстерү институтын формалаштыру турында

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән тәү күздә тотылган Татарстан Республикасы фармацевтика сәнәгатен үстерү институтын формалаштыру һәм Татарстан Республикасы фармацевтикасы өлкәсендә фәнни-белем бирү потенциалыннан файдалануның нәтиҗәлеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасының фармацевтика сәнәгатен үстерү максатларында Татарстан Республикасына резидентларны адреслы җәлеп итү һәм урнаштыру өчен Татарстан Республикасы ФармМедПолисы концепциясен;

Татарстан Республикасының фармацевтика сәнәгатен үстерү максатларында Татарстан Республикасына резидентларны адреслы җәлеп итү һәм урнаштыру өчен Татарстан Республикасы ФармМедПолисы концепциясен тормышка ашыру буенча 2018 – 2022 елларга чаралар планын (алга таба – Чаралар планы).

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын Чаралар планын тормышка ашыру буенча эшләр координаторы итеп билгеләргә.

3. Территорияләрендә фармацевтика производстволарын урнаштыру күздә тотылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына әлеге производстволарны урнаштыру өчен шартлар тудыру өчлешендә Чаралар планын тормышка ашыруда катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин